ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**02.06.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1227**

2021 елның II кварталына гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында

Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 7 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Законы һәм әлеге күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 26 февралендәге 94/пр номерлы «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының 2021 елның беренче яртыеллыгына бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча 2021 елның II кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» боерыгы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 91.3 статьясына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2021 елның II кварталына гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-1 006 452 сум;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен-2 012 904 сум;
1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен-3 019 356 сум;
1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен - 4 025 808 сум;
1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен-5 032 260 сум;
1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 6 038 712 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 7 045 164 сум.

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-15 394,73 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 15 394,73 сум;

1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 15 394,73 сум.

2. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда, «ЗМР Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән иң чик күрсәткечләрне кулланырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә начальнигына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев